**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 17 сентябрь № 683

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары мөлкәтен карап тотуга нормативлар чыгымнарны раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 807 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары мөлкәтен карап тотуга нормативлар чыгымнарны раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 807 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 3 март, 128 нче, 2015 ел, 20 апрель, 269 нчы, 2015 ел, 3 июнь, 398 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасының дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары интернатлары мөлкәтен карап тотуга база норматив чыгымнарына карата төзәтү коэффициентлары;

Татарстан Республикасы дәүләт һөнәр белеме бирү оешмаларын финанс ягыннан тәэмин итү күләменә төзәтү коэффициентлары»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары мөлкәтен карап тотуга база норматив чыгымнарын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары мөлкәтен карап тотуга база норматив чыгымнары

| Т/с | Урта буын белгечләрен әзерләү программаларын гамәлгә ашыручы, шулай ук тулай торакларда (интернатларда) торак урыннар белән тәэмин итүче һөнәр белеме бирү оешмасы төре | Мөлкәтне карап тоту нормативы, айга сум/кв.метр |
|---|---|---|
| 1. | Техникум, көллият, училище, институт | 48,56 |
| 2. | Тулай торак | 65,75 |
| 3. | Интернат | 41,98»; |

әлеге карарга 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә Татарстан Республикасының дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары интернатлары мөлкәтен карап тотуга база норматив чыгымнарына карата төзәтү коэффициентларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт һөнәр белеме бирү оешмаларын финанс ягыннан тәэмин итү күләменә төзәтү коэффициентларын өстәргә

2. Бу карарның көче 2015 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала, дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\683.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 17 сентябрь, 683 нче
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасының дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары интернатлары мөлкәтен карап тотуга база норматив чыгымнарына карата төзәтү коэффициентлары

| Т/с | Учреждение исеме | Төзәтү коэффициенты | Ягып җылытылган мәйдан, кв.метр |
|---|---|---|---|
| 1. | «Казан хореография училищесы» Татарстан Республикасының урта һөнәр белеме бирүче дәүләт автоном учреждениесе | 1,2572 | 1551,5 |

_______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 17 сентябрь, 683 нче
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы дәүләт һөнәр белеме бирү оешмаларын финанс ягыннан тәэмин итү күләменә төзәтү коэффициентлары

| Т/с | Учреждение исеме | Төзәтү коэффициенты |
|---|---|---|
| 1. | «Казан хореография училищесы» Татарстан Республикасының урта һөнәр белеме бирүче дәүләт автоном учреждениесе | 1,03488 |

F:\KARAR\2015\683.docx